«Раслыйм»
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
территориясен планлаштыру проектлары
һәм межалау проектлары буенча
комиссия рәисе»

________________________И.Ф. Рәхимов

№ 6
2021 елның 26 мае

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясен межалау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү

**БӘЯЛӘМӘСЕ**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының «Территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2021 елның 29 апрелендәге 4 номерлы карары белән билгеләнгән ачык тыңлаулар 2021 елның 26 маенда 10 сәгать 00 минутта Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129-нчы йорт.

2021 елның 26 маендагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясен межалау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе

**Ачык тыңлаулар предметы:**

1. «Инженерлык системалары һәм Технологияләр» ҖЧҖнең, Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Вәлиев урамы һәм Яшьләр урамы чикләрендәге территорияләрне межалау проектын карау турында мөрәҗәгате, әлеге проектлар белән https://chistopol.tatarstan.ru/dokumenti-564409.htm сылтамасы буенча танышырга мөмкин.

**Карар иттеләр:**

1. Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Вәлиев урамы һәм Яшьләр урамы чикләрендәге территорияләрне межалау проекты буенча ачык тыңлауларны узган дип санарга.
2. Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Вәлиев урамы һәм Яшьләр урамы чикләрендәге территорияләрне межалау проектын эшләп бетерүгә җибәрергә.
3. Яшьләр урамы чикләрендәге территорияне межалау проектын «Челтәр компаниясе» ААҖ Чистай электр челтәрләре белән килештерергә.
4. Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Вәлиев урамы һәм Яшьләр урамы чикләрендәге территорияләрне межалау проектын эшләп бетерү зарурлыгына бәйле рәвештә, ачык тыңлауларны 2021 елның 12 июлендә 10 сәгать 00 минутта Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында уздырырга.
5. Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: ____________________Бибишев М.Р.